Казан шәһәре Совет  районы “Күп профильле 181 нче мәктәп”
№3 ноябрь, 2020 ел

# «Күкнең җиденче катында»

Бу санда:

1. Әниләр көне
2. Мәктәбебез тормышы “кайнап” тора
3. “Бәллүр каләм” бәйгесе
4.Юбиляр язучылар
Мәктәп викторинасы

## Әниләр көне

Әни… Өч хәрефтән торган бу сүздә күпме  җылылык!  Һәр кеше өчен иң кадерле кеше ул! Аның йомшак куллары безгә кагылуга, бөтен кайгылар югала.

Әни! Нинди ягымлы да сүз ул!  Әни өйгә килеп керү белән, өй яктырып китә. Әни үзенең карашы  белән безне һәр яктан саклый һәм яклый кебек.

Мөхәммәт пәйгамбәрнең: «Һәр бөек эшнең артында хатын-кыз тора. Ул уң кулы белән бишек, сул кулы белән бөтен дөньяны тибрәтә», — дигән сүзләре һаман актуаль булып кала. Хатын-кыз нәфис иңенә, бала карау, гаилә мәшәкатьләреннән тыш, ил хәстәрен дә ала. Гүзәл затларыбыз җәмгыятьнең төрле даирәләрендә үзләрен белемле белгечләр, яхшы хезмәткәрләр итеп таныта. Көндәлек эшеннән тыш, хатын-кыз ул — милләт анасы. Әйе, болай атау һич арттыру түгел. Әни кешенең бурычы — баласының тамагын тук, өстен бөтен итүдә генә түгел, ә нарасыен милләтенең асылташы итеп тәрбияләүдәдер. Баланың теле әнисе сөйләшкән телдә ачыла. Бу — бер. Икенчедән, бала үз халкының гореф-гадәтләре, дини бәйрәмнәре, йолалары тәэсирендә дә тәрбияләнергә тиеш. Ә аларны кем бирә? Әлбәттә, әни. Үзенең телен, милли традицияләрен, тамырларын белгән балалар тәрбияләү — һәр ананың бурычы. «Дөньяга килгән сәгать белән балалар тәрбиягә мохтаҗлардыр. Боларны тәрбияләүчеләр дә — аналардыр. Аналар балаларның һәр эшләрен гадәткә салырлар. Тәрбияле аналар — олуглар алдында эшләргә ярамаган эшләрне балалар алдында эшләмәсләр вә сөйләргә ярамаган сүзләрне сөйләмәсләр, моннан бик сакланырлар. Шулай ук балаларның хәйләгә, ялган сөйләргә өйрәнүләренә сәбәп булырдай нәрсәләрне кылмаслар», — дип әйтелә «Тәрбияле ана» исемле хезмәтендә. Аллаһының мең рәхмәте яусын сезгә, кадерле әниләр!

Мәктәбебездә әниләр көне уңаеннан бик күп бәйгеләр, кызыклы чаралар үткәрелде. Матур теләкләр язылган “Серле чәчәкләр”, эчтәлекле хатлар, кул эшләре күргәзмәсе, иншалар, сыйныф сәгатьләре...

Укучыларыбыз бәйгеләрдә бик теләп катнаштылар.









## Халыкара толерантлык көне

16 ноябрь - Халыкара толерантлык көне. Әлеге төшенчә барлык кешегә дә таныш булмаска мөмкин. Тик аның мәгънәсе кешелек җәмгыятенең үсеше өчен бик әһәмиятле булып тора. Заманча мәдәниятле кеше — ул укымышлы гына түгел, ә башкалар тарафыннан хөрмәткә ия һәм үз-үзен ихтирам итүче кеше дә.

Нәрсә соң ул толерантлык? Фәлсәфи энциклопедиядә бу сүзгә түбәндәге аңлатма бирелгән: толерантлык (латинча tolerantia — түземлелек) — иkенче, башка төрле карашларга, холыкка, гореф-гадәтләргә түземлелек. Ә чит телләр сүзлегендә “толерантлык – чит фикерләргә һәм чит диннәргә карата түземлелек” дип бирелә.

Без, 181 нче мәктәп укучылары, барыгызны да кешеләргә карата түземле, кешелекле, шәфкатьле булырга чакырабыз!

## Юл фаҗигасендә үлүчеләрне искә алу көне

2005 елдан башлап ноябрьнең өченче якшәмбесе юл фаҗигасендә үлүчеләрне искә алу көне итеп билгеләп үтелә.

Төп максаты – юл-транспорт һәлакәтендә үлүчеләрне тагын бер кат искә алу һәм шулай ук аварияләрнең күп булуына игътибарны юнәлтү.

Юл-транспорт һәлакәтендә үлүчеләрнең күбрәк (15-25 яшь) яшьләр арасында булуы бигрәк тә аяныч.

Юл-транспорт һәлакәте булмасын өчен, юл хәрәкәтендә катнашучыларның барысының да кагыйдәләрне төгәл үтәве нәтиҗәсендә генә ирешеп була. Беребезгә дә якыннарыбызны югалту ачысын татырга язмасын, юлларда исән-имин йөрик!!!

## “Бәллүр каләм” бәйгесе

### Әнием - назлы гөлем

Минем әниемнең исеме – Гөлназ. Исеменең мәгънәсе “назлы гөл”. Әниемне гөлләр белән чагыштырып була, ул көннән-көн яшәрә, чибәрләнә.

Әбием аңа Миләүшә исеме бирергә теләгән була, ләкин апасының кызы үз сүзендә нык тора: Гөлназ исемен куштыра. Әниемнең әйтүе буенча, ул үскәндә бик популяр исем була, сыйныфында 4 Гөлназ укый.

Әнием тумышы белән Балтач якларыннан. Белемне Балтач мәктәбендә ала. Мәктәпне яхшы билгеләргә тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты һәм чит телләр факультетына укырга керә. 3 ел укыгач, әнием Казанның бер мәктәбенә укытучы булып эшкә урнаша. 2 елдан диплом алып, шул мәктәптә эшләп кала.

Әнием кечкенәдән балаларны бик ярата. Хыялы - балалар белән эшләү була.

Хәзерге көндә кечкенә вакытындагы хыялы тормышка ашты, балалар бакчасында эшли. Үз эшенә карата бик төгәл.  Гел эзләнә, яңалыкка омтыла. Әле кечкенә балаларга күп мәгълүмат бирергә, барысына өйрәтергә, тормышка карата мәхәббәт тәрбияләргә ашыга.

Өйдә әнием таләпчән; 3 баласының, укымышлы, тәртипле, тыйнак, эшчән булуын тели. Төрле милли ашлар пешереп сыйлый, гөлләр үстерә. Җәй көне бакчада эшләргә ярата, яшелчәләр үстерә, көз көне бай уңыш ала.

Бәйли, чигә, өйдә дә гел яңалык кертеп тора.

Без  әниебезне бик яратабыз. Безнең әни дөньяда бер генә.

Асланова  Нәргиз, 7 нче Б сыйныф укучысы

## Минем әнием

Әнием – минем иң кадерле кешем. Мин аны бик яратам һәм әниемнең кадерен беләм.

Әнием минем бик тә матур. Аның кояштай елмаюын, нур чәчеп торучы ягымлы күзләрен, йомшак, назлы кулларын яратам.

Әнием - бик яхшы,  изге күңелле кеше. Аны барысы да ярата, хөрмәт итә.

Ул миңа авыр минутларымда булыша, үзенең төпле фикерләре, киңәшләре белән уртаклаша, моңсу булганда, кызык мәзәкләр сөйләп, юата.

Әнием бик тәмле ашлар, ризыклар пешерә. Мин аңа бу эштә булышам. Ул мине тормышта кирәкле һәм файдалы белемнәргә өйрәтә.

Мин әниемә һәр көнне рәхмәтлемен.

Камалова Самира, 6 нчы А сыйныф укучысы

## Татарстан Республикасының юбиляр язучылары, шагыйрьләре

- Этнограф, тарихчы, дин эшлеклесе Корбангали Халидинең тууына 175 ел (1846–1913)
- Педагог, мөхәррир, дәреслекләр авторы Харис Зариф улы Фәйзуллин (Фәйзи-Чистапули)ның тууына 150 ел (1871–1933)
- Татар әдәбияты классигы, драматург, шагыйрь, фольклорчы Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзинең (Фәйзуллинның) тууына 130 ел (1891–1928)
- Әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Башкортстан АССРның атказанган фән эшлеклесе Әхәт Зәйнетдин улы Нигъмәтуллинның тууына 100 ел (1921–2015)
- Әдәбият галиме, педагог, журналист, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре Альберт Гатуф улы Яхинның тууына 90 ел (1931–2010)
- Язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Леронга (Лемон Лерон улы Лероновка) 60 яшь (1961)

## Мәктәп ВИКТОРинасы

1. Нинди саннар “боера” ала?
2. Агачка унике карга кунган. Аучы килеп икесен аткан. Агачта ничә карга калган?
3. Беренче иҗеге – җирнең иярчене; икенче иҗеге – җәзалау урыны; кушып укыганда – кеше исеме.
4. Бер иҗегем башта, икенчесе – кышта; кушып укысаң икесен, эт исемен әйтерсең.
5. Исемнән – фигыльгә, фигыльдән – исемгә. Исемнәрне кушымчалар ярдәмендә фигыльгә, фигыльләрне яңадан исемгә әйләндерегез.
6. Сулдан уңга, уңнан сулга бер үк төрле укыла торган нинди исемнәр беләсез?
7. Ялагай, алачак сүзләрен өлешләргә бүлеп тагын нинди дүртәр сүз ясарга мөмкин?
8. Панама, Дүшәмбе, Вена, Бостон – ялгызлык исемнәрен юл( кечкенә) хәрефе белән язганда алар нәрсә аңлаталар?
9. Исемнән – сыйфатка, сыйфаттан - исемгә. Исемнәрне кушымчалар ярдәмендә сыйфатка, сыйфатларны яңадан исемгә әйләндерегез.

Редакциянең адресы:
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
Тираж – 50 экз.
Баш мөхәррир һәм дизайнер:
Габдуллаҗанова А.Ф.
Редколлегия әгъзалары: Сафина Камилла, Соколова София, Овезова Ләйлә, Закирова Азалия